КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 август г.Казань № 639

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның фәнни-техник, инновацион, шул исәптән нанотехнологик тармакларны, фәнни-техник мәгълүмат системасын, интеллектуаль милек базарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 26 октябрь, 804 нче карары белән расланган Юридик затларның фәнни-техник, инновацион, шул исәптән нанотехнологик тармакларны, фәнни-техник мәгълүмат системасын, интеллектуаль милек базарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның фәнни-техник, инновацион, шул исәптән нанотехнологик тармакларны, фәнни-техник мәгълүмат системасын, интеллектуаль милек базарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 26 октябрь, 804 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 гыйнвар, 17 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның фәнни-техник, инновацион, шул исәптән нанотехнологик тармакларны, фәнни-техник мәгълүмат системасын, интеллектуаль милек базарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документлар юридик затлар тарафыннан кәгазь чыганакта яки электрон рәвештә тапшырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Тапшырылган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен юридик зат Россия Федерацииясе законнары нигезендә җавап тота.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин